| СОВЕТ ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**10.06.2026** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 33** |

Зеленодольск шәһәре Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу белешмәләрне бозып бирү җитди булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибе хакында» 2020 елның 15 октябрендәге 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 33-ФЗ номерлы, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законнар, 2017 елның 19 июлендәге ««Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе хакында» 56-ТРЗ номерлы, 2017 елның 19 июлендәге «Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнары нигезендә, Татарстан Республикасының Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең Уставы белән, Зеленодольск шәһәре Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск шәһәре Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу белешмәләрне бозып бирү җитди булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибе хакында» 2020 елның 15 октябрендәге 7 номерлы карарына (2023 елның 30 мартындагы 114 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:: ««Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу белешмәләрне бозып бирү җитди булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибе хакында»;

1.2. карарның преамбуласындагы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы» сүзләрен ««Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы» сүзләре белән алыштырырга, «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе хакында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы» сүзләрен « ««Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе хакында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ » сүзләре белән алыштырырга;

1.3. карарның 1 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук хатынының (иренең) һәм

балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозып бирү җитди булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибе расларга (Кушымта).»

2. Карар Кушымтасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.1. карар Кушымтасының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

««Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар биргән өчен, әгәр бу белешмәләрне бозып бирү җитди булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибе »;

2.2. Кушымтаның 1 нче пунктына үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затына (алга таба- муниципаль вазыйфаны биләүче зат) карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре (алга таба - керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр) турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозып бирү җитди булмаса, җаваплылык чаралары (алга таба – җаваплылык чаралары) куллану процедурасын регламентлый.»;

2.3. Кушымтаның 2 нче пунктындагы беренче абзацында «2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законының 40 нчы статьясының $7^{3-1}$ нче өлешендә күчерелгән» сүзләрен «2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законының 29 нчы статьясының 4 нче өлешендә күчерелгән» дигән сүзләргә алыштырырга.

2.4. Кушымтаның 2 нче пунктындагы икенче абзацында «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 40 нчы статьясының $7^{3}$ нче өлешендә каралган» сүзләрен «Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясындагы 7.2 өлешендә каралган» дигән сүзләргә алыштырырга.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан

Республикасы муниципаль берәмлекләренең (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) порталында бастырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

**Зеленодольск шәһәре Хакиме,**
**Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**